ЯКШӘМБЕ
3 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 2 (6724)
Аерым номеры 15 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Москва, Кремль, иптәш СТАЛИНГА

Татар халкыннан бөек Сталинга сәлам!

Тамбов патриотларына Сез җибәргән котлауны укып чыкканнан соң Орденлы Татарстан колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары болай диделәр: «Бөек баһадир Сталин безне көрәшкә һәм җиңүгә чакыра. Туганыбыз Кызыл Армиягә күп танклар, пушкалар һәм самолетлар бирик. Безнең батыр егетләребез явыз дошманны тәмам җимерсеннәр». Безнең республикабызның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, тирән патриотизм хисе белән сугарылган хәлдә, «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә акча җыюга керештеләр. Алар үзләренең саклык акчаларыннан 100 миллион сум керттеләр. Акча керү дәвам итә. Азатлык сөюче татар халкының бу яңа бүләге немец оккупантларны безнең тәмам җиңүебез көнен якынайтуда батыр Кызыл Армиягә булышлык итсен.

Татарстан колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызларының тапшыруы буенча Сезне, Иосиф Виссарионович, яңа ел белән котлыйбыз. Сезгә күп көч, озын гомер һәм сәламәтлек телибез.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре КОЛЫБАНОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Совнаркомы Председателе ГАФИЯТУЛЛИН.

КАЗАН

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре КОЛЫБАНОВКА Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе ДИНМӨХӘМЕТОВКА Татарстан АССР Совнаркомы Председателе ГАФИЯТУЛЛИНГА

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының „Татарстан колхозчысы" исемле танклар колоннасы төзелешенә 100 миллион сум акча җыйган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ЮЛБАШЧЫБЫЗНЫҢ КОТЛАВЫНА КОНКРЕТ ЭШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРИК!

Бүген республикабызның колхозчылары, колхозчы хатын-кызлары һәм барлык хезмәт ияләре гаять шатлыклы хәбәр алдылар. Газетабызның бүгенге номерында бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталинның ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре Колыбанов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Динмөхәметов һәм ТАССР Совнаркомы Председателе Гафиятуллин иптәшләр исеменә җибәргән телеграммасы урнаштырыла. Иптәш Сталин телеграммасында болай ди:

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 100 миллион сум акча җыйган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН».

Республикабызның колхозчылары юлбашчыбызның телеграммасы белән урынлы рәвештә горурлана алалар. Алар үз теләкләре белән, үзләренең намус хезмәтләре белән табылган средстволарыннан «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасына кыска гына вакыт эчендә 100 миллион сум акча җыеп, Госбанкның урындагы бүлекләренә тапшырдылар.

100 миллион сум! Явыз һәм кабахәт дошманны кыру өчен сугыш машиналары дигән сүз ул. Бу, илебезнең башка өлкәләрендәге һәм республикаларындагы шикелле үк, безнең республикабыз колхозчыларының да патриотлык үрнәге дигән сүз. Бу фактта безнең республикабыз колхозчыларының да үз Ватаннарына, большевиклар партиясе эшенә, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин эшенә һәм Совет хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгәнлекләре ачык чагыла.

Тамбов өлкәсе колхозчыларының инициативасы безнең республикабыз колхозчылары арасында да киң җирлек тапканын бөтен ачыклыгы белән әйтергә кирәк. Республикабызның һәрбер районында колхозчылар «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә средство туплауда бик актив катнаштылар. Бөгелмә, Ворошилов, Саба, Чүпрәле, Дөбьяз һәм тагын күп кенә башка районнардагы колхозчыларның аеруча актив катнашуларын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Мондый районнарда 2—3 көн эчендә миллионнарча сум акча тупланды. Колхозчы-патриот Ферапонт Головатый үрнәге дә республикабызда бик тиз эләктереп алынды. Үзләренең саклык акчаларыннан 5 мең сум, 10 мең, 20 мең, 30 мең һәм 50 мең сум күләмендә акча кертүче колхозчылар аз булмады һәм ул массовый төс алды.

Дошман тар-мар ителергә, сытып ташланырга тиеш һәм ул, һичшиксез, юк ителер! Ләкин моның өчен оешканлык, үз-үзеңне аямыйча хезмәт итү, сөекле Кызыл Армиягә эшлекле ярдәм кирәк. Башкача булуы мөмкин түгел һәм совет крестьяннары моны яхшы аңлыйлар. Шуның өчен дә алар бернәрсәләрен дә кызганмыйлар һәм үзләренең матур тормышларын, колхоз байлыгын саклап калу өчен Кызыл Армиягә һәрьяктан ярдәм итәргә әзер торалар. Танклар колоннасы төзүгә акча җыю, дәүләт йөкләмәләрен тулысынча үтәгәннән соң, үзләренең запасларыннан Кызыл Армия фондына дистәләрчә, йөзләрчә пот ашлык тапшыру моны ачык расласа кирәк.

Республикабызның колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавы һәм рәхмәте — ул безнең колхозчы крестьяннарыбыз өчен горурлык. Ләкин ул шул ук вакытта алар алдына зур бурычлар да куя. Кызыл Армиябезнең һөҗүме тагын да көчлерәк булсын өчен, ударлары тагын да катырак һәм куәтлерәк булсын өчен аңа ярдәмебезне торган саен арттыра барыйк, үзебезнең намуслы хезмәтебез белән дошманның үлем сәгатен якынайтыйк. Бөтенесе дә фронт өчен! Бөтенесе дә дошманны тармар итү өчен!

Юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавына һәм рәхмәтенә лаеклы булган колхозчыларга һәм колхозчы хатын-кызларга дан һәм хөрмәт!

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

ҮЗӘК ФРОНТТА безнең гаскәрләр, кискен штурм нәтиҗәсендә, **ВЕЛИКИЕ ЛУКИ** шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Коралын ташлаудан баш тартканлыктан шәһәрнең немецлар гарнизоны кырып бетерелде.

СТАЛИНГРАДТАН көньяктарак безнең гаскәрләр **ЭЛИСТА** шәһәрен алдылар.

СТАЛИНГРАДТАН көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр район үзәге **ТОРМОСИННЫ** алдылар.

ТӨНЬЯК КАВКАЗДА безнең гаскәрләр район үзәге **ЧИКОЛАНЫ** алдылар.

Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ

СУГЫШЧАН ТУГАНЛЫК

ҮЗӘК ФРОНТ. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Сугышка кадәр Ленинград заводларыннан берсенең эшчесе, хәзер кызыл командир майор иптәш Максимов бүген сугышка алып барган батальонда СССР дагы 16 халыкның—рус, украин, татар, башкорт, үзбәк, казак, азербайҗан, бурят-монгол һ. б: ның вәкилләре бар: Батальон әле беренче тапкыр сугышка керә иде. Сугышчылар, 100 километр марш үткәннән соң, халык яши торган ике зур пункт арасындагы шоссе юлы өстендә урнашкан һәм кечә генә немецлардан тартып алынган бер авылга урнашып ныгый башладылар. Бер тәүлек үткәннән соң авыл өстенә немецларның 40 бомбардировщигы килеп чыкты. Шул ук минутта дошманның артиллериясе ут ачты. Ә тагын ярты сәгатьтән соң авылга 20 танк һөҗүм итте.

СССР дагы 16 милләтнең вәкилләреннән торган батальон сугышчыларының фронттагы беренче сыналулары шундый шартларда башланды.

Сугышчылар бомбалар һәм снарядлар ярылудан казыган воронкаларга яттылар һәм гранаталар әзерләделәр. Кызылармеец, рус егете П[illegible]нков граната ыргытып немецларның бер машинасын шартлатты. Татар егете бронебойщик Ибраһимов беренче атудан ук дошманның икенче танкысын яндырды. Шуннан соң яшь сугышчылар канатланып киттеләр. Берничә минуттан соң дошманның тагын 2 танкысы яна башлады, аннары тагы икесенә ут кабынды.

Майор Максимов һәрвакыт яшь сугышчылар арасында булды һәм аларга җитәкчелек итте.

Немецларның атакасы кире кайтарылды. Ләкин төнлә, дошман авылны яндыргыч снарядлар белән коендыра башлады. Барлык йортлар да диярлек яндылар. Ә иртә белән немецлар батальонның тылына үтеп керүгә ирештеләр. Һәрвакыт дошман уты астында торган тар гына юл белән Максимов сугышчыларны күрше авылга алып чыкты.

Майор Максимовка бер генә төрле юл бар иде—кичекмәстән немецларга каршы барырга һәм аларны штык сугышына мәҗбүр итәргә. Яшь сугышчылар мондый омтылышлы адымга сәләтлеләрме соң? Ләкин башка төрле карарга килү мөмкин түгел иде, һәм, майор кызылармеецларны атакага күтәрде.

16 халыкның яшь сугышчыларыннан торган батальон дошманга шундый көч белән удар ясады ки, менә сыналган фронтовиклар да сокланырлар иде.

Нәтиҗәдә майор Максимов көткәннән күп артык булды. Батальон немецларны таркатты һәм аларның артыннан куа барып, гел штык белән генә сугышып та, авылга бәреп керде, аннан немецларны куып чыгарды һәм яңадан анда ныгып урнашты.

И. ДЕНИСОВ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

1 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

1 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинградтан** көньяктарак, урта **Дон** районында һәм **Үзәк фронтта** элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең частьлар сугыша-сугыша алга бардылар, 2 кварталны һәм дошманның берничә дистә ДЗОТ ын һәм блиндажларын алдылар. Дошман, үтерелгән хәлдә, 200 дән артык солдат һәм офицерын югалтты.

* * *

Сталинградтан төньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр актив сугыш хәрәкәтләре алып бардылар һәм үзләренең позицияләрен яхшырттылар. Бер участокта совет подразделениеләре бер биеклекне алдылар һәм немецларның 100 гә якын солдат һәм офицерын юк иттеләр. Ике орудие, 7 пулемет һәм 3 миномет кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н че часть дошманның ике контратакасын кире кайтарды һәм бер ротага якын гитлерчыларны кырып ташлады, немецларның 10 танкысын яндырды һәм 4 танкысын сафтан чыгарды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Сталинградтан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманны куып баруда дәвам иттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н че часть танкистлары немецларның танкка каршы ата торган 9 орудиесен, 23 пулеметын, 38 автомашинасын юк иттеләр һәм дошманның 300 дән артык солдат һәм офицерын кырып ташладылар. 65 пленный алынды. Икенче бер участокта уңайлы позицияләргә ныгып урнашкан немецлар совет частьларының алга баруларын тоткарларга маташканнар иде. Безнең сугышчылар дошманның артыннан әйләнеп чыктылар һәм аңа тылдан удар ясадылар. Бик каты сугышта дошманның 400 солдаты һәм офицеры кырып ташланды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Урта Дон районында безнең гаскәрләр һөҗүм алып бардылар һәм аерым участокларда дошманның контратакаларын кире кайтардылар. **Н че гвардия часте, уңышлы рәвештә алга барып, халык яши торган өч пунктны алды. 16 орудие, 45 автомашина, 4 радиостанция кулга төшерелде һәм дошманның 450 солдаты һәм офицеры плен алынды. Участокларның берсендә немецлар пехотасы һәм танклары контратака ясаганнар иде. Безнең** подразделениеләр гитлерчыларның контратакасын кире кайтардылар һәм аларны элекке позицияләренә чигенергә мәҗбүр иттеләр. Дошман, тик үтерелгән хәлдә генә дә, 300 гә якын солдат һәм офицерын югалтты.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Великие Луки районында совет частьлары дошманның күп кенә ныгытылган оборона узелларын алдылар һәм 400 дән артык солдат һәм офицерын юк иттеләр.

Ржевтан көнбатыштагы районда безнең сугышчылар дошманның берничә атакасын кире кайтардылар. 100 гә якын гитлерчыны кырып ташладылар һәм немецларның 7 танкысын җимерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда хәрәкәт итүче «Буря», «Орел» һәм «Вихрь» дигән партизан отрядлары немец басып алучыларга каршы сугышларда немецларның 184 солдат һәм офицерын кырып ташлаганнар. Төньяк Кавказ партизаннары отрядларыннан берсе хәрби эшелонны юлдан чыгарган. Һәлакәт вакытында немец солдатлары һәм офицерлары төялгән 14 вагон ватылган. 400 гә якын гитлерчы үтерелгән.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр, Ленинград өлкәсендәге Голубово авылында торучыларга карата ерткычлыклар эшләгәннәр. 17 нче декабрьда төнлә белән немецлар авылга һөҗүм итеп кергәннәр, барлык крестьяннарны, семьялары белән бергә, колхозның ат абзарына куып кертканнәр һәм аларны бикләп куйганнар. Колхозчыларның барлык йортларын бөтенләй талап бетергәннән соң, бандитлар авылны яндырганнар. Гитлерчы палачлар ат абзарында хатын-кызлар һәм балалар күз алдында 12 картны атып үтергәннәр. Шунда ук гитлерчылар барлык кешеләрнең җылы киемнәрен, киез итекләрен салдырып алганнар, ә соныннан өс һәм аяк киемсез калган бу кешеләрне конвой астында мәҗбүри эшләргә куып алып киткәннәр.

* * *

Немец оккупантларга каршылык күрсәтүнең үскәнлеге турында Чех-Словакиядән хәбәр итәләр. Брнодагы бер хәрби заводта чех патриотлары чертежларны урлаганнар һәм Германия армиясе өчен корал эшләп чыгаруны өзгәннәр. Пильзендагы бер хәрби заводта күп кенә орудиеләр һәм пулеметлар брак итеп эшләп чыгарылганнар. Немецларның махсус техник комиссиясе барлык орудиеләрне һәм пулеметларны бракка чыгарган. Шул уңай белән гестапочылар 60 тан артык эшчене һәм инженерны кулга алганнар. Берничә көннән соң чех патриотлары заводтагы ике цехны сафтан чыгарганнар.

1 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

1 нче январьда безнең гаскәрләр **Донның** урта агымы районында, **Сталинградтан** көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, **Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең гаскәрләр **Великие Луки** шәһәрен һәм тимер юл узелын, **Элиста** шәһәрен, район үзәкләреннән **Тормосинны** һәм **Чиколаны** һәм халык яши торган зур пунктлардан **Нижне-Курмоярскаяны, Балабановскийны, Березканы, Баклановскийны, Жуковскаяны, Кривскойны, Мало-Лучнаяны, Степано-Разинскийны, Комаровны, Красный Ярны, Верхне-Солоновскийны, Нижне-Солоновскийны, Поповны, Хазнидонны** һәм **Толдзгунны** алдылар.

* * *

31 нче декабрьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 50 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 7 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, ике ротага якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, 100—300 метр алга киттеләр. Дошманның бик күп ДЗОТ лары һәм блиндажлары юк ителде. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. 6 пулемет, берничә миномет һәм 20.000 патрон кулга төшерелде.

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең частьлар дошманга каршы атака ясадылар һәм уңайлы позицияләр алдылар. Сугыш кырында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре һәм сафтан чыгарылган 5 танкысы калды. 8 пулемет, 3 миномет, танкка каршы ата торган 11 мылтык, бер радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Сталинградтан көньяктарак безнең частьлар, бик каты сугыштан соң, Элиста шәһәрен алдылар. Немецлар гаять зур югалтуларга дучар ителделәр. Өлкән лейтенант Дмитриев командалыгындагы танкистлар чигенүче дошманга атака ясадылар, 300 дән артык гитлерчыны кырып ташладылар һәм дошманның 12 орудиесен юк иттеләр. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары бер батальонга якын гитлерчыларны кырдылар, 400 кешене плен алдылар һәм дошманның 6 төзек танкысын кулга төшерделәр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Обливская районында совет частьлары 50 дән артык орудие, 50 автомашина, 12 трактор, 1.500 винтовка, бер артиллерия склады, 3 азык һәм 3 кием-салым склады, бер он склады, ашлык тутырылган бер элеватор, бер ягулык склады, инженерлык милекләре саклана торган склад һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Немецлар тарафыннан хәрби корылмалар төзелешенә куылган 3.000 совет гражданы азат ителде. Н-че часть сугышчылары алга таба барып, 600 немец солдатын һәм офицерын кырдылар, дошманның 10 орудиесен, 15 автомашинасын һәм 20 повозкасын юк иттеләр.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Кискен штурм нәтиҗәсендә безнең частьлар Великие Луки шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Коралын ташлаудан баш тартканлыктан шәһәрнең немецлар гарнизоны кырып бетерелде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары дошманның берничә оборона узелын алдылар. 200 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Сугыш кырында дошманның бик күп үле гәүдәләре калды.

* * *

Нальчиктан көньяк-көнчыгыштарак безнең гаскәрләр район үзәге Чиколаны һәм халык яши торган пунктлардан Хазнидонны һәм Толдзгунны алдылар. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта Терек елгасы аша үтеп чыккан безнең частьлар дошманны кысрыклауны дәвам иттерделәр һәм немецларның ике ротага якын пехотасын, 4 орудиесен һәм 4 миномётын юк иттеләр.

Гвардия капитаны Кабицкий командалыгындагы батарея берничә сәгать эчендә дошманның 5 станоклы пулеметының утын бастырды һәм сугыш йөкләре төялгән 13 автомашинаны юк итте.

* * *

Ленинград фронтында безнең снайперлар ике көн эчендә 380 дошман солдатын һәм офицерын кырдылар. Артиллерия уты белән дошманның танкка каршы ата торган 3 орудиесе, 4 миномет батареясы, 10 автомашинасы сугыш йөкләре төялгән берничә повозкасы юк ителде, 26 ДЗОТ ы һәм блиндажы җимертелде.

* * *

Смоленск өлкәсенең немецлар оккупацияләгән районнарының берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның ике эшелонын юлдан чыгарган. Төрле йөкләр төялгән 12 вагон, гаскәрләр төялгән 8 вагон, автомашиналар төялгән 17 платформа һәм бензин тутырылган 3 цистерна җимерелгән. Смоленск партизаннарының икенче бер отряды немецларның гаскәри частена каршы сугыш алып барган. Бу сугышта совет патриотлары 68 гитлерчыны кырып ташлаганнар.

2 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Донның** урта агымы районында, **Сталинградтан** көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, **Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең подразделениеләр берничә йортны, дошманның 39 ДЗОТ ын һәм блиндажын алдылар. 100 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. **Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең частьлар бик каты сугыш нәтиҗәсендә дошманның уннарча окопларын һәм блиндажларын алдылар. Немецлар, югалткан позицияләрен кайтарырга омтылып, берничә тапкыр контратака ясадылар, ләкин уңышка ирешә алмадылар. Дошманның бер ротага якын пехотасы кырып ташланды һәм 7 танкысы юк ителде. 4 танк, 21 пулемет, 85 винтовка һәм 14 автомат кулга төшерелде.**

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Немецлар чигенгән чакта бик күп техникаларын, төрле коралларын, сугыш снаряжениеләрен һәм милекләрен ташлап калдыралар. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышларда Н-че часть 300 дән артык немец солдатын һәм офицерын юк итте, 135 кешене плен алды. 8 орудие, 17 пулемет, төрле йөкләр төялгән 28 автомашина һәм бер азык склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта совет танкистлары бер дошман батальонын тармар иттеләр. Сугыш кырында 400 дән артык немец солдатларының һәм офицерларының үле гәүдәләре калды. 100 кеше плен алынды.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары уңайлы чикләрне саклаучы дошманның каршылык күрсәтүен туктаттылар. Сугыш нәтиҗәсендә 7 танк сафтан чыгарылды. Немецлар чигенгән чакта 3 самоход орудиеләрен, 8 минометларын, күп кенә снарядларын һәм патроннарын калдырдылар. Икенче бер участокта безнең мотопехотабыз халык яши торган бер пунктны алды һәм 230 дошман солдатын һәм офицерын плен алды

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар, ә аерым участокларда дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Луки шәһәрен алган безнең частьлар бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Ржевтан көнбатыштагы районда дошманның зур берләшмәсе, танклар ярдәме белән, безнең позицияләргә берничә тапкыр атака ясарга маташып карады. Бу позицияләрне саклап торучы Н-че часть сугышчылары гитлерчыларның барлык атакаларын кире кайтардылар һәм аларны элекке позицияләренә алып ташладылар. Немецларның 6 танкысы яндырылды һәм берничә йөз дошман солдаты һәм офицеры юк ителде.

* * *

Калинин өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды соңгы көннәрдә 40 немец солдатын үтергән, шоссе юлларында 8 күперне яндырган һәм фашистларның 11 волость управасын туздырган. Калинин партизаннарының икенче бер отряды әһәмиятле тимер юл магистралендәге бер күперне шартлаткан. Шул ук отряд партизаннарының кечерәк бер группасы, засададан торып, 18 гитлерчыны кырган һәм сугыш припаслары төялгән 8 автомашинаны юк иткән.

* * *

Түбәндә немец-фашист кабахәтләр тарафыннан Ростов өлкәсе, Озеры хуторында совет хәрби пленныйларына һәм совет гражданнарына карата эшләнгән коточкыч ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Без, түбәндә кул куючылар, бу актны шушы турыда төзедек: Кызыл Армия частьлары Ростов өлкәсендәге Озеры хуторын азат иткәннән соң без, немецлар тарафыннан хәрби пленныйлар өчен ясалган лагерьны карадык. Лагерь хуторның төньяк читендә, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган 3 терлек абзарында ясалган. Лагерь территориясе немецлар тарафыннан ерткыч төстә газаплап үтерелгән гражданнарның һәм кызылармеецларның үле гәүдәләре белән тулган. Гитлерчы палачлар 4 ай эчендә 260 хәрби пленныйны һәм тирә-як авыллардан җыеп китерелгән гражданнарны ачлык белән кырганнар һәм үтергәннәр. Лагерьда 240 кеше калган. Шулардан 100 дән артык кеше аякларына басып тора алмыйлар. Аларның барысының да эренле яралары бар, аяк һәм куллары өшегән. Фашистлардан тоткынлыктан азат ителгән Георгий Макушев, Исмаил Пыреев, Максим Мартынец, Андрей Гордеев, Иван Масырчук һәм күп кенә башка кешеләр немецларның аларны тәүлегенә 20 шәр сәгать буена җир казу эшендә эшләргә мәҗбүр иткәнлекләрен әйттеләр. Лагерьда тоткыннарга бөтен көн буена бары 100 грамм икмәк һәм көрпәдән пешерелгән бер кружка боламык биргәннәр. Гитлерчы ерткычлар авыру һәм хәлсез кешеләрне таяклар белән кыйнаганнар, ә бөтенләй хәлдән тайганнарны штыклар белән кадап үтергәннәр. Лагерь территориясендә үләрлек хәлгә килеп җиткән 16 яшьлек Александр Морозкин табылды. Анда ул күргән газаплар һәм җәзалаулар аны картайтканнар. Аның чәчләре агарган, битендә тирән җыерчыклар ясалган. Совет врачлары аны коткару өчен бөтен көчләрен бирделәр, ләкин соң иде инде һәм ул озакламый үлде». Актка капитан Ляпин, капитан Хованов, капитан Гаркуша, лейтенант Красношеков, лейтенант Доронин һәм өлкән сержант Медведевлар кул куйдылар.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЧАЛЛЫ РАЙОНЫ, МОЛОТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ

Колхоз председателе иптәш МӘРДИЕВКӘ

Молотов исемендәге колхозның колхозчыларыга аларның Кызыл Армия турында кайгыртучанлык күсәтүләре өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

* * *

И. СТАЛИН.

Колхозчыларның эшлекле җавабы

Митинг булачагы бөтен авылга ишен тизлеге белән таралды. Колхозчыларның күбесе килеп чакырганны да көтмичә клубка килә башладылар. Митинг билгеләнгән вакыт җиткәндә колхоз клубы шыгрым тулы иде инде. Даһи юлбашчының котлавын тизрәк ишетәселәре килде колхозчыларның.

Митинг башланды. Колхоз председателе иптәш Мәрдиев, өстенә кызыл комач япкан өстәл янына килеп басты да, бераз дулкынланган тавыш белән, Иосиф Виссарионович Сталиннан килгән телеграмманы укый башлады. Колхозчылар юлбашчының сәламен һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен, тын да алмыйча, дулкынланып тыңладылар. Һәркемнең сөйлисе, юлбашчының котлавына чын күңелдән җавап бирәсе килде. Иптәш Мәдриев та митингта үзенең җавабын белдерергә ашыкты. Ул:

— Колхозыбызга танклар колоннасы төзүгә күп кенә акча туплаганы өчен бөек юлбашчы Кызыл Армиянең рәхмәтен белдерде. Минем ике улым фронтта. Фронтта һәрберебезнең дә якыннары бар. Шулар хакына мин тагын 25 пот ашлык бирәм,—диде.

Моннан соң чыгып сөйләүчеләрнең дә сүзләре кыска булды. Колхозчылардан Җамалиева, Шакиров, Ахунова иптәшләр дә героик Кызыл Армия фондына берәр центнер ашлык бирергә теләүләрен белдерделәр.

Шулай итеп митинг юлбашчының котлавына чын күңелдән эшлекле җавап бирү тантанасына әверелде. 65 яшьлек бабай Шиһабиев та картларча салмак адымнар белән алгарак чыкты да:

— Мин карт инде. Үзем фронтка барып сугыша алмыйм. Үз көчем белән эшләп тапкан икмәгем белән сугышчыларга булышыйм дим, һәм 9 пот ашлык бирәм,—диде.

Юлбашчыга чын патриотларча җавап бирү теләге белән рухланган колхозчылар батыр сугышчылар өчен 450 пот ашлык бирделәр.

Чаллы районының Молотов исемендәге колхоз патриотларының бөек юлбашчыга җавабы шул.

КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫН КҮП ҖИТЕШТЕРИК

Сугыш шартларында районнарда җирле промышленностьны үстерүнең әһәмияте тагын да үсте. Беренчедән, колхозларга һәм колхозчыларга кирәкле киң куллану товарларының бер өлешен урында җитештереп, су һәм тимер юл транспортын, ниһаять җирле транспортны бу нәрсәләрне ташудан бушатуның хәзерге шартларда гаять зур әһәмияте бар.

Бу өлкәдә үткән елда Беренче Май районында шактый нәрсәләр эшләнде. Июль аенда район үзәгендә промкомбинат оештырылды. Комбинат предприятиеләрендә шушы чор эчендә 21,5 тонна деготь кайнатылды һәм 15 мең данә балчык савыт эшләнде. Ноябрь аенда тире иләү мастерскоe оештырылды һәм анда 200 дән артык тире иләнде.

Яңа елда промкомбинатның эшен тагын да киңәйтү бурычы куелды һәм киез итек басу, сабын кайнату, янавыч эшләү предприятиеләре оештыру планлаштырылды. Шулай ук бу предприятиеләрнең продукция бирүләре дә нык үсәргә тиеш. Мәсәлән, быел 65 тонна деготь кайнату, 50 мең данә балчык савытлар эшләү, 2.500 пар киез итек басу, 10 тонна сабын кайнату, 10 мең данә янавыч эшләп чыгару планлаштырылды.

Промкомбинат системасыннан тыш районда тагын берничә артель бар. «1 нче Май» артелендә өс киемнәре, аяк киемнәре тегү, парикмахерская, фотография һәм бәйләү цехлары эшли. Бу артельнең аерым цехлары яхшы гына күрсәткечләр бирделәр. Парихмахерская һәм фотография 1942 нче елның еллык планын декабрь башына ук арттырып үтәделәр. Индивидуаль яңа киемнәр тегү буенча еллык план 45 мең сумлык урынына декабрь башына 65 мең 512 сумлык итеп үтәлде.

«1 нче Май» лесхозы (директоры иптәш Хөснетдинов) 1942 нче ел планын уңышлы гына үтәде һәм 20 мең сум урынына 21 мең сумлык продукция эшләп чыгарды. **Лесхозда 190 данә тугым, 100 данә чана, 200 данә чана табаны, 400 данә дуга һ. б. эшләнде. Шулай ук Чирмешән лесхозының Лашман пункты да планны тулысынча үтәде. Ул 77 арба, 300 чана һәм 300 чана табаны эшләде, 60 тонна урынына 90 тонна күмер яндырды.**

Җирле промышленность предприятиеләре һәм артельләрнең җитәкчеләре үз эшләрендә хуҗаларча кайгыртучанлык һәм инициатива күрсәткән вакытта урында киң куллану товарлары җитештерүне тагын да киңәйтергә мөмкин. Мәсәлән, агачтан табак-савыт эшләү, каеш эшләү, камыт, ыңгырчак кебек сбруйлар эшләүне һичбер тоткарсыз күпләп җитештерергә була. Моның өчен урында материал һәм чимал җитәрлек. Кайбер хуҗалык оешмаларының җитәкчеләре («Наша путь» артеле һ. б.), эшче көчләр юк, дип зарланырга яраталар. Бу һич тә дөрес түгел. Урында эшче көчләр бар һәм җитәрлек. Ләкин алардан дөрес файдалана белүче генә юк. Бу предприятиеләргә өйрәнчекләр алу, кайбер белгечләр буенча кыска сроклы курслар оештыру, эшкә күбрәк хатын-кызларны тарту кебек конкрет чаралар үткәрелми. Бу өлкәдә Җирле промышленность халык комиссариаты да бик начар шөгыльләнә. Киләчәктә менә бу чараларны үткәрергә һәм районнарда җирле промышленностьны үстерүдә чын-чынлап шөгыльләнергә кирәк.

Ш. ДӘҮЛӘТШИН,
райплан председателе.

5 СӘГАТЬ 35 МИНУТКА ЭЛЕК

Юдино депосы машинисты Белянкин, аның ярдәмчесе Белков һәм кочегар Самохвалов иптәшләр поездлар йөртүдә бик яхшы күрсәткечләр бирәләр. 29 нчы декабрьда бригадага Юдинодан Вятские Polяныга йөксез поезд алып бару тапшырылды. Поезд юлга шактый соңга калып чыгуга карамастан, иптәш Белянкин аны Вятские Поляны станциясенә расписаниедә күрсәтелгәнгә караганда 5 сәгать 35 минутка элек алып барып җиткерде.

Художник Н. Сокольскийның яңа ел плакаты.

Кадерле якташларга

Кадерле аталарыбыз һәм аналарыбыз, туганнарыбыз һәм сеңелләребез, хатыннарыбыз һәм балаларыбыз, кадерле якташларыбыз—Татарстан хезмәт ияләре!

Сугыш кырларыннан сезгә үзебезнең фронт сәламнәребезне җибәрәбез һәм сезне яңа, 1943 нче ел белән котлыйбыз!

Бу көнне без һәрвакыт сезнең белән бергә каршылыйбыз. Һәм, сәгать төнге 12 не суккач, без бер-беребезне кочаклап, сезнең белән бергә, башлана торган яңа елны, шатлык һәм хезмәт елын, чын кешеләрчә тормышның яңа елын котлыйбыз.

1943 нче елны без Ватан сугышы шартларында каршылыйбыз һәм ерак фронттан сезгә, кадерлеләр, үзебезнең Яңа ел сәламнәребезне җибәрәбез.

1943 нче ел яңа җиңүләр китерсен, фашизмны тар-мар итүне китерсен! Без үзебезнең сугышчан байракларыбызны көнбатышка таба җиңүле рәвештә алып барырга Сезгә ант итәбез!

Яңа ел Ватан хакына, фронтка ярдәм итү хакына үз үзеңне аямыйча нәтиҗәле хезмәт итү елы булсын!

Яшәсен безнең җиңү!

Яшәсен безнең юлбашчыбыз һәм остазыбыз, бөек полководец иптәш Сталин!

Генерал-майор Н. ОРЛОВ.

КАВИ НӘҖМИ

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Кичәгенәк төнлә
Кремльнең
Сәгать чаңы сукты:
Уникe...
Һәм үткән ел әйтте:
— «Бу унике
Соңгы минутына хәтле
Минеке!
Ил башына төшкән авырлыкны
Минем белән бергә күрде ул
Һәм тарихка
Җиңү бәйрәменең
Таң шәүләсе булып керде ул.
Бу минутта барлык кешеләр
Өйрәнделәр яңа гадәткә,—
Төн уртасы җиткән саен көтеп
Таныш сүзне:
— Соңгы сәгатьтә!»
...Ленин мавзолее янында
Часовойлар кичек алмашса,—
Яңа ел да шулай
Кичекмичә
Иске елга
Килде алмашка.
Сәгать сукты тәгәл уникe.
Җил туктады.
Буран басылды.
Үткән елның актык сүзе белән
Яңа елның теле ачылды:
— Соңгы сәгать!
— Кемгә?
— Гитлерга!
Соңгы сәгать фашист этләргә!
Ул сәгатьне—җиңү сәгатен
Туры килмәс озак көтәргә!

МОСКВА МЕТРОПОЛИТЕНЫНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ЧИРАТТАГЫ ТӨЗЕЛЕШЕ ЭШЛИ БАШЛАДЫ

1943 нче елның беренче көнендә башкаланың хезмәт ияләре яңа бик әйбәт бүләк алдылар. Москва метрополитенының өченче чираттагы төзелеше эшли башлады.

6,2 километр озынлыктагы яңа җир асты юлы шәһәрнең үзәген—Свердлов мәйданын — Москваның промышленность районнары белән тоташтыра.

Метрополитенның өченче чиратын төзегән вакытта 700.000 кубометр балчык чыгарылды, 200.000 кубометрга якын бетон һәм 100.000 тонна тюбинглар салынды. Метроның Москварецкий радиусы Москва елгасын тирән җир астыннан 4 тапкыр аркылы үтеп чыга. (ТАСС).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

2 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

2 нче январьда безнең гаскәрләр **Донның** урта агымы районында, **Сталинградтан** көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, **Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең гаскәрләр район үзәге **Дубовскоены**, тимер юл станциясе **Ремонтнаяны** һәм район үзәге **Эльхотовоны** алдылар.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы һәм разведка алып бардылар. Заводлар районында штурм группалары дошманның берничә терәк пунктын алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда 200 дән артык гитлерчы юк ителде.

* * *

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең сугышчылар немецларны 25 блиндаждан һәм окоптан бәреп чыгардылар, 3 орудие, 3 миномет, 6 пулемет, 50 винтовка, 500 мина һәм күп кенә патроннар кулга төшерделәр. 80 гитлерчы үтерелде. Пленныйлар алынды. Совет частьлары кулындагы территориягә немецларның азык төягән бер транспорт самолеты төште. Самолетның экипажы плен алынды.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга барып, халык яши торган берничә пунктны, шул исәптән район үзәге Дубровскоены һәм тимер юл станциясе Ремонтнаяны алдылар. Дубовскоеда һәм тимер юл станциясе Ремонтнаяда бик күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында танклар, артиллерия һәм азык складлары һәм төрле сугыш милекләре бар. Бик күп терлекләр кулга төшерелде. Элиста шәһәре өчен булган сугышта совет гаскәрләре немецларның моторлаштырылган 60 нчы полкын, сапер батальонын, моторлаштырылган 156 нчы полкның бер батальонын һәм дошманның башка частьларын һәм подразделениеләрен тар-мар иттеләр. Безнең хәрәкәттәге отрядларыбыз, чигенүче дошманны куып барып, 800 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар, 200 кешене плен алдылар, 6 орудие, күп кенә пулеметлар, автомашиналар һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть, алга таба барып, халык яши торган, немецлар алган 2 зур пункт арасындагы юлны кистеләр. 300 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Күрше участокта дошманның контратакасы кире кайтарылды, немецларның 16 танкысы җимертелде һәм яндырылды. Безнең бер разведка отряды немецларның пехота полкы штабын туздырды һәм шул вакытта бер группа офицерларны, шулай ук полк командиры булган полковникны юк итте. Штаб документлары кулга төшерелде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Великие Лукидан көнбатыштагы районда Н-че часть сугышчылары немецларны ныгытылган позицияләреннән бәреп чыгардылар, дошманның 5 танкысын, 160 солдатын һәм офицерын юк иттеләр. Ржевтан көнбатыштагы районда иптәш Ильяшенко командалыгындагы сугышчылар соңгы сугышларда немецларның берничә частен һәм подразделениеләрен тар-мар иттеләр. Операцияләр барышында дошманның 49 танкысы, 9 бронемашинасы һәм 30 автомашинасы юк ителде.

* * *

Нальчиктан көньяк-көнчыгыштарак Н-че берләшмә сугышчылары дошман кулындагы Эльхотово район үзәген әйләнеп үттеләр һәм анда бәреп кerделәр. Урам сугышларында 400 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Кичкә таба безнең частьлар Эльхотовоны алдылар. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманга атака ясадылар һәм сугыш нәтиҗәсендә зур әһәмияте булган оборона чиген алдылар. Бу сугышта гитлерчыларның берничә йөз солдаты һәм офицеры үтерелде. Дошманның 14 танкысы һәм бер бронемашинасы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче, Щорс исемендәге отрядның һәм «Смерть немецким оккупантам» исемле отрядның партизаннары дошманга каршы 4 көн дәвам иткән сугышларда 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иткәннәр. Курск пртизаннарының бер отряды немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 5 вагон һәм бер паровоз җимерелгән. Күп вагоннар һәм платформалар зарарланган.

* * *

Полтава шәһәрендә немец-фашист кабахәтләр эшләгән канлы җинаятьләр турында хәбәр алынды. Соңгы ике ай эчендә генә дә гитлерчылар 1.000 нән артык кешене үлгәнче газаплаганнар һәм атып үтергәннәр. Немецлар шәһәрдә һәм аның тирә-ягында берничә төрмә һәм концентрация лагерьлары ясаганнар. Алар барысы да тоткыннар белән тулган. Декабрьның икенче яртысында немецлар берничә йөз кешене, шул исәптән Германиягә Гитлер каторгасына барудан баш тарткан 65 тимер юлчыны төрмәгә япканнар. Аларны җәзалап үтерүләре куркынычы бар. Полтава төрмәсеннән качкан Иван Дорошенко немец палачларның тоткыннарны ерткычларча газаплауларын сөйләде. Төрмә ишек алдында немецлар дар агачлары ясаганнар. Палачлар һәр көнне 5–10 кешене асып үтерәләр. Декабрь башларында камераларда берничә кеше өшеп үлгән.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ СУГЫШТАГЫ УҢЫШЛАРЫ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

АКШ

„Дон сахралары—Германия өметләренең кабере“

НЬЮ ЙОРК, 1 январь. (ТАСС). Кызыл Армиянең сугыштагы уңышлары Америка матбугатының башлыча темасы булып тора. Кызыл Армия частьларының Котельниковоны алулары турындагы хәбәр зур заголовоклар астында газеталарның беренче битләрендә, иң күренекле урыннарда басылып чыкты.

«Нью Йорк таймс» газетасы болай яза: «Сталинград районында Гитлер үзенең позицияләрен ныгытырга бөтен көчләре белән маташып карады. Гитлер гаскәрләренең хәзерге чигенүләре, җәйге һөҗүмнәренә караганда тагын да кыйммәткәрәк төшә. Дон сахралары немец солдатларының кабере булып әверелә. Бу кабергә Германиянең җиңүгә булган өметләре дә күмелде. Россиягә каршы сугышның бу икенче кышында Германия халкы үзенең интереслары Гитлерның басып алу теләкләренә корбан ителгәнлекне тагын да ачыграк аңлар. Котельниково шәһәренең һәм станциясенең Кызыл Армия частьлары тарафыннан алынуы Гитлер планнарының җимерелгәнлегенә бер дәлил булып тора. Кызыл Армия алга баруында дәвам итә». Аннары газета болай яза:

«Узган елгы вакыйгалар кабатлана, ләкин быелгы кыш көнендә немец гаскәрләренең чигенүләре, узган кышка караганда да, ачыграк тар-мар ителүне күрсәтә. Үз көчләренең зәгыйфьләнүе сәбәпле немецлар узган җәй көне бөтен фронт буйлап һөҗүм итә алмадылар, быелгы кыш көнендә алар ял итәргә һәм үзләренең көчләрен яңартырга булдыра алмыйлар, чөнки аларга Кызыл Армиянең кысрыклавы белән һәм Африкада союзниклар гаскәрләренең хәрәкәтләре белән исәпләшергә туры килә».

«Нью-Йорк геральд трибюн» газетасы: «Көньяк фронтта немецларның хәле шактый начарланды. Руслар немецларның иң әһәмиятле позицияләренә якынлашып килəләр»,—дип яза.

АНГЛИЯ

„СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ҺӨҖҮМЕ ҖИҢҮЛЕ РӘВЕШТӘ ҖӘЕЛӘ“

ЛОНДОН, 1 январь. (ТАСС). Англия матбугаты Кызыл Армия частьларының һөҗүме турындагы хәбәрләрне киң рәвештә аңлатуда дәвам итә.

«Дейли мейл» газетасы, 1942 нче елда Совет—Германия фронтындагы вакыйгаларга күзәтү ясаганнан соң, бу фронтта Гитлерның планнары бөтенләй җимерелде, дигән нәтиҗәгә килә. «Дейли телеграф энд морнинг пост» газетасы да шундый ук нәтиҗәгә килә. Газета болай яза: «1942 нче елда Совет—Германия фронтындагы көрәшнең йомгаклары Кызыл Армия өчен яхшы булып торалар. Дошман үзенең төп максатларыннан берсенә дә ирешә алмады, ә хәзер Кызыл Армия бик зур уңыш белән һөҗүм алып бара». Газета, Кызыл Армия частьлары тарафыннан Котельниковоның алынуы, фронтның бу участогында Германия гаскәрләренең хәлен шактый начарлата, дип яза.

«Таймс» газетасы да шулай ук, хәзер Котельниково руслар кулында булгач, немецлар контратакалар алып барырлык бик яхшы базаларыннан мәхрум булып калдылар, дип яза. Соңгы сугыш операцияләрендә руслар иң кыен шартларда да хәрәкәт итәргә сәләтле икәнлекләрен тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

Рейтер агентлыгының хәрби күзәтүчесе генерал Губерт Гоф болай яза: «Совет гаскәрләренең һөҗүме уңышлы рәвештә җәелә. Шул уңай белән Англиядә, вакыйгаларга бик саклык белән карый торган хәрби күзәтүчеләрнең дә, Гитлер гаять зур җиңелү алдында тора, дип әйтүләре һич тә гаҗәп түгел. Бик тизлек белән алга бара торган Совет гаскәрләренең удары алдында Германия гаскәрләренең рухы төшә һәм бу хәл Гитлер өчен аеруча күңелсез булырга тиеш».

ТӨРКИЯ

„РУСЛАРНЫҢ УДАРЛАРЫ АСТЫНДА ГЕРМАНИЯ ФРОНТЫ КАЛТЫРЫЙ“

ИСТАМБУЛ, 1 январь. (ТАСС). Кызыл Армия частьларының һөҗүме Төркия газеталарында күренекле урынны алып тора. Бу һөҗүм уңае белән газеталарда киң аңлатмалар бирелә. «Сон телеграф» газетасының хәрби күзәтүчесе болай яза: «Кискен һөҗүм алып баручы русларның ударлары астында Германия фронты калтырый. Немецлар соңгы айларда бик тырышып әзерләгән кышкы позицияләреннән бәреп чыгарылдылар. Ныгытмаларыннан мәхрум булып калган немец дивизияләренең көче кимеде. Немецлар контратакалар ясап, үзләренең хәлен яхшыртырга уйлаганнар иде, ләкин алар моны булдыра алмадылар. Рус армиясе уңышлы рәвештә һөҗүмне дәвам иттерә. Германия гаскәрләре җитди куркыныч алдында торалар.

«Ени сабах» газетасы үзенең баш мәкаләсендә Кызыл Армия частьларының һөҗүме Германиянең көньяктагы армияләре өчен җитди куркыныч тудыра, дип яза.

Германияне яклавы белән мәгълүм булган генерал Эркилет та «Җөмһүрият» газетасында, Сталинградтан көньяктарак немецларның хәле куркынычлы, дип яза. «Руслар бу һөҗүмдә инициативаны үз кулларына алдылар, шунлыктан алар немецларның каршы эшләнә торган чараларын кыенлаштыралар. Бу хәл русларга инициативаны үз кулларында тотарга мөмкинлек бирә».

ФРАНЦИЯНЕҢ ТӨНЬЯК АФРИКАСЫНДА КУЛГА АЛУЛАР

Кулга алынучылар Жирога һәм Мэрфига һөҗүм әзерләгән булганнар

ЛОНДОН, 31 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 29 нчы декабрьда кич белән Алжир полициясе 12 кешене кулга алган. Аларның күпчелеге югары власть вәкилләрен үтерергә әзерләнүдә гаепләнәләр. Кулга алынучыларның дүртесе—полиция работниклары. Алар Дарланны үтерергә әзерлек турында белгәннәр булырга кирәк дип уйлыйлар. 29 нчы декабрьда Франция Төньяк Африкасының верховный комиссары генерал Жиро, кулга алынучылар арасында үзенең иң яхшы дусларыннан да берничә кеше булганлыгын белдергән.

Кулга алынучыларның бер өлеше генерал Жироны һәм АКШ президенты Рузвельтның Төньяк Африкадагы вәкиле Мэрфины үтерү максаты белән заговор ясауда гаепләнәләр. Кулга алынучылар арасында бик зур дәрәҗәле ике кеше дә бар.

Генерал Жироның әйтүенә караганда, кулга алынучылар илдә төрле кешеләрне үтерергә һәм тәртипсезлекләр чыгарырга әзерләнгән булганнар. Алар Төньяк Африкада электән торучы кешеләр булырга кирәк дип уйлыйлар.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ

ПИОНЕРЛАР ЙОРТЫНДА ЕЛКА

Балаларга культура хезмәте күрсәтүне тагын да яхшырту теләге белән Казан пионерлары һәм мәктәп балалары йорты Бутлеров урамындагы яңа бинага күчерелде. Каникул көннәрендә—1 нче январьдан алып 10 нчы январьга кадәр—анда шәһәр күләмендә елка үткәрелә. Пионерлар йорты матур итеп бизәлде. Төрле бүлмәләргә елкалар куелды, ял бүлмәләре җиһазландырылды.

Балалар өчен һәркөн өчәр тапкыр концертлар, кино-сеанслар, дәүләт курчак театрының постановкалары оештырыла. Татарстанның атаклы кешеләре белән, шулай ук бөек Ватан сугышында катнашучылар белән балаларның очрашулары була.

10 нчы классларда укучылар өчен 6 нчы январьда бал-маскарад үткәрергә билгеләнде. Елкага килүче балаларга бүләкләр өләшенә.

* * *

Мәктәпләрдәге кышкы каникуллар вакытында шәһәрнең Сталин районында хәрби-физкультура уеннары оештырыла. «Спартак» стадионында 700 пар чаңгы әзерләнде. Өлкән классларда укучылар 10—15 километрга чаңгы походына баралар. Күп кенә мәктәпләр янында кар таулары һәм ике урында каток ясалды.

Кабан күле өстендә төрле спорт ярышлары үткәреләчәк. Барлык мәктәпләрдә укучылар өчен елкалар янында концертлар бирелә.

Районда гимнастика мәктәбе ачылды. Мәктәп төрле спорт кирәк-яраклары белән җиһазландырылды. Анда йөзгә якын яшь үсмерләр бокс, фехтование һәм башка гимнастика уеннарын өйрәнәләр.

* * *

Молотов районының Белинский исемендәге урта мәктәбендә укучылар каникулларны тулы әзерлек белән каршыладылар. Укучыларның үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре һәртөрле концерт номерлары әзерләделәр. Ватан сугышы фронтларында катнашучылар белән очрашулар үткәрелә. Пушкин һәм Чайковскийга багышланган әдәби-музыкаль кичә ясала. «Дуслык һәм мәхәббәт» дигән темага диспут оештырыла.

Мәктәптә укучылар тарафыннан оборона, санитария, физкультура һәм үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре төзелде. Каникул көннәрендә балалар өчен циркка һәм театрларга культпоходлар оештырыла.

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Мәктәпләрдә кышкы каникуллар вакытында «Совет халкының бөек Ватан сугышы» күргәзмәсенә экскурсияләр оештырыла. Күргәзмәдә Ватан сугышына карата беседалар, лекцияләр, Советлар Союзы Геройлары белән һәм Ватан сугышы фронтларында катнашучылар белән очрашулар үткәрелә.

Күргәзмә дүшәмбе көннәрдән башка һәр көн 10 сәгатьтән 18 сәгатькә кадәр эшли.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 601 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 19